**Карар**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**

Чубар-Абдул авылы №164 «30» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2020 елга
муниципаль милекне хосусыйлаштыруның
фаразланган планын раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге №178-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2016 елның 21.10.2016 елнын 44 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә белән:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразланган планын расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитетына 2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразланган планын гамәлгә ашыруны тәэмин итүне киңәш итәргә.

3. Әлеге карарны, сатуларны үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән, Россия Федерациясенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес : http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru, рәсми басма - «Татмедиа» филиалы «Маяк» район газетасында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Ә. Фәтхетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге советы карарына кушымта
«30»декабрь 2019 №164

# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразланган планы

1 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразланган планы (алга таба - фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге № 178-ФЗ Федераль закон нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 октябрь 44 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә белән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычларын, чикләүләрен һәм үзенчәлекләрен билгели.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең муниципаль милеген хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга, кучемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, җирле бюджет кытлыгын муниципаль милек сатудан керемнәр белән каплау чыганакларын формалаштыруга юнәлдерелгән.

3. «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге № 178-ФЗ Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны ТР Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул Чубар-Абдул авыл җирлеге муниципаль милкендәге күчемсез милек объектларын һәм күчемсез милекне сату юлы белән аукционда яки конкурста һәм законда каралган башка ысуллар белән үткәрү күздә тотыла.

4. Медпункт зданиясе муниципаль милек объектының агымдагы елда сатылмавын исәпкә алып, аны 2020 елга фараз планына кертергә кирәк.

5. 2020 елда муниципаль казнадагы түбәндәге муниципаль милекне хосусыйлаштырырга тиеш:

| п/п | Исеме һәм төп характеристикалары | Адрес | Сатуларны үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Медпункт зданиясе | Чубар-Абдул авылы , Яшьләр урамы 1 йорт 2 кв. | 2 ярты еллык |

6. Фаразланган планга кергән муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар кабул итү Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан, 2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон нигезендә, Азнакай муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру буенча комиссия тәкъдимнәре нигезендә тормышка ашырыла.

7. Фаразланган планга кермәгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар кабул итү Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан, 2001 елның 21 декабрендә кабул ителгән 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон нигезендә, Азнакай муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру буенча комиссия тәкъдимнәре нигезендә тормышка ашырыла.

8. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыруны оештыруга һәм үткәрүгә акчалар түбәндәге чыгым төрләре буенча тотыла дип билгеләргә:

- мөлкәтне сатуга әзерләү, шул исәптән техник һәм кадастр документларын рәсмиләштерү;
- базар бәясен һәм башлангыч бәяне билгеләү өчен мөлкәтне бәяләү;
- сатып алучылар тарафыннан үз йөкләмәләренең үтәлешен исәпкә алу һәм контрольдә тоту буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең судларда мөлкәти һәм башка хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;
- мәгълүмат-коммуникация системаларын булдыру һәм аларга хезмәт күрсәтү, милекне сатуның матди-техник базасын камилләштерү.